ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.03.2020 № 274

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасында мөрәҗәгать итүчеләр һәм документлар белән эшләүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге административ регламентларына үзгәрешләр кертергә:

- Торак биналарны гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта);

- Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (14 нче кушымта);

- Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (15 нче кушымта);

- Муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында муниципаль милекне рәсмиләштерү (беркетү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (28 нче кушымта);

- Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген даими (сроксыз) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (29 нчы кушымта);

- Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (30 нчы кушымта);

- Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (31 нче кушымта );

- Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә генә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (32 нче кушымта);

- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату-алу үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (33 нче кушымта);

- Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (34 нче кушымта);

- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (35нче кушымта);

- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда җир кишәрлеген сату юлы белән милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (36нчы кушымта);

- Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (37 нче кушымта);

- Муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (38 нче кушымта);

- Крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген башкару өчен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына муниципаль милектәге җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (39 нчы кушымта);

- Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (40 нчы кушымта);

- Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга бакчачылык алып бару өчен милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (41 нче кушымта);

- Хосусый яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башка категориягә күчерү турында Карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (43 нче кушымта);

- Җир кишәрлегеннән даими (сроксыз) файдалану хокукын яки җир кишәрлегенә гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында Карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (44 нче кушымта);

- Җир кишәрлеген сатып алу турында Карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (45 нче кушымта);

- Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (46 нчы кушымта);

- Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (47 нче кушымта);

- Муниципаль милек булган җир кишәрлекләрендә клад Эзләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (48 нче кушымта);

- Муниципаль преференцияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (49 нчы кушымта);

- Җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламент (53 нче кушымта);

- Муниципаль милектә булган һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (54 нче кушымта );

- Казан шәһәре муниципаль милкен арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (55 нче кушымта);

- Муниципаль милектә булган җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (56 нчы кушымта);

- Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (57 нче кушымта);

- Муниципаль милек реестрына керүче муниципаль милекне арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (58 нче кушымта);

- Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән файдалану төрен үзгәртү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (59нчы кушымта);

- Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек, дача коммерцияле булмаган берләшмәсе әгъзасы булган гражданга түләүсез җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (60 нчы кушымта);

- Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль милекне файдалануга тапшыру һәм (яки) файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (62 нче кушымта);

- Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек, дача коммерцияле булмаган берләшмәсе милкенә караган җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (63 нче кушымта);

- Муниципаль берәмлек мөлкәтен сатулар үткәрмичә генә түләүсез файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (65 нче кушымта);

- Мондый шартнамә төзү хокукына аукцион нәтиҗәләре буенча муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсен төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (66 нчы кушымта);

- Объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында Карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (67 нче кушымта);

- Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга шәхси торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (69 нчы кушымта);

- Муниципаль милекне арендалау шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (70 нче кушымта) (алга таба – регламентлар).

1.1. Регламентларның 1.3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның урнашу урыны: Кама Тамагы штп., Калинин ур., 31.

Эш графигы: дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Палатаның урнашу урыны: Кама Тамагы ш.т. б., Калинин ур., 7.

Палатаның эш графигы: дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Гариза бирүчеләрне Палата белгечләре кабул итү графигы: Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00 дән 16.30 га кадәр

Ял һәм ашау өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмә өчен телефон: 8(84377)21090.

Керү, шәхесне раслаучы документлар буенча».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе С.В. Головинга йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин